

# КАЗАНЫШЛАРЫБЫЗ ЕЛЪЯЗМАСЫ

Тукай премиясе — Дәүләт бүләге буларак (элегрәк Республика **премиясе** дип атала иде) — Татарстан Республикасының иң югары һәм иң абруйлы **премиясе.** Аның башлангычы 1958 елга барып тоташа. Мәгълүм булганча, тоталитар **режим** йомшый, җәмгыятьтә демократик яралгылар шыта башлаган чор бу.

**"Әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә иҗат активлыгын тагын да күтәрү максаты белән, КПСС өлкә комитеты бюросы һәм Татарстан АССР Министрлар Советы әдәбият, музыка һәм сынлы сәнгать өлкәсендә идея эчтәлеге һәм художество дәрәҗәсе ягыннан аеруча әһәмиятле әсәрләр һәм сәхнә әсәрләрен иң яхшы башкару өчен республика күләмендә Г. Тукай исемендәге премияләр билгеләргә кирәк дип таптылар... Премияләр ел саен Татарстан АССР төзелү еллыгы көнендә — 25 июньдә — Республика премияләр комитеты карары белән биреләчәк".**

Шулай итеп 1958 елда кабул ителгән бу карар нигезендә, премияләрне бирү тәртибе билгеләнә, Республика премияләре комитеты раслана. Комитетның беренче рәисе — К. Ф. Фасиев. 14 кешедән торган комитет әгъзалары арасында Г. Бәширов, Н. Җиһанов, Н. Даутов, Х. Якупов, Н. Якушенко, Г. Камай кебек күренекле шәхесләрнең исемнәре бар. Шул ук елны комитет тарафыннан беренче лауреатлар билгеләнә һәм Республика җитәкчелеге тарафыннан раслана. Беренче лауреатлар шактый ишле — әдәбият, музыка, сынлы сәнгать, театр өлкәсеннән җәмгысы 11 кеше. Дөрес, кайбер елларда (1961 — 1965, 1975) премия (сәбәп-мотивлары безгә төгәл аньк түгел — ред.) бөтенләй бирелмәгән. Кырык ел эчендә бу мактаулы исемгә 118 кеше һәм 1 иҗади оешма (Татарстан Дәүләт җыр һәм бию ансамбле) лаек булган. Шунысы да гыйбрәтле: лауреатлар арасында төрле милләт кешеләре бар — татар, рус, үзбәк, немец, башкорт, яһүд... Бу факт премиянең демократик рухта, интернациональ асылда булуы турында сөйли. 1979 елдан Тукай премиясе Дәүләт премиясе статусын алды. Соңгы дистә елларда Премия алган кешеләрнең исемнәре, Тукай туган көнне — 26 апрельдә — игълан ителә. Яңа лауреатлар, кагыйдә буларак, шул ук көнне Шигырь бәйрәмендә җыелган халык алдына чыгалар һәм нотык тоталар.

Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре 1991 елга кадәр партия өлкә комитеты һәм Татарстан Министрлар Советы карары белән бирелде, ә 1992 елдан Татарстан Президенты Указы белән бирелеп килә. Лауреатларга лауреатлык дипломы һәм медале, гадәттә, Республика көне (30 август) алдыннан тапшырыла.